МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.12.2024 Казан ш № 819

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер тапкыр пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгы белән расланган Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер тапкыр пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер тапкыр пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.09.2014 №490, 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №400, 08.06.2017 №348, 17.11.2017 №809, 07.05.2018 №353, 18.09.2018 №885, 08.07.2019 №532, 03.09.2019 №665, 14.11.2019 №1017, 28.02.2020 №142, 09.07.2020 №491, 08.10.2020 №708, 24.03.2021 №154, 17.11.2021 №849, 30.11.2022 №1064, 24.11.2023 №912 боерыклары нигезендә кертелгән

үзгәрешләре белән) белән расланган Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер тапкыр пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2024 елның
13 декабрендәге 819 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер тапкыр пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгы белән расланган Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер тапкыр пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.2.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. Дәүләт хезмәте «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» (алга таба - Үзәк) дәүләт казна учреждениесе тарафыннан Үзәкнең Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы бүлекчәсе (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) аша мөрәҗәгать итүченең яшәү (тору) урыны буенча яисә расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта – фактта яшәү урыны буенча күрсәтелә.»;

2.7 пунктның бишенче абзацында «(тору) яисә расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта – фактик яшәү урыны буенча түгел» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән Регламентка 1 нче кушымтада:

«(мөрәҗәгать итүченең индексын, телефонын, электрон почта адресын күрсәтеп почта адресы)» сүзләрен «(почта индексы, яшәү (тору) урыны буенча теркәлү адресы яисә расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта – мөрәҗәгать итүченең фактта яшәү урыны, телефон, электрон почта адресы)» сүзләренә алмаштырырга;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

«яшәү (тору) урыны буенча» сүзләреннән соң «яисә расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта – фактта яшәү урыны» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән Регламентка 2 нче кушымтада:

«(мөрәҗәгать итүченең индексын, телефонын, электрон почта адресын күрсәтеп почта адресы)» сүзләрен «(почта индексы, яшәү (тору) урыны буенча теркәлү адресы яисә расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта - мөрәҗәгать

итүченең фактта яшәү урыны, телефон, электрон почта адресы)» сүзләренә алмаштырырга;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

«яшәү (тору) урыны буенча» сүзләреннән соң «яисә расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта – фактта яшәү урыны» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән Регламентның 6 нчы кушымтасында «(мөрәҗәгать итүченең индексын күрсәтеп почта адресы, телефоны, электрон адресы)» сүзләрен «(почта индексы, яшәү (тору) урыны буенча теркәлү адресы яисә расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта – мөрәҗәгать итүченең фактта яшәү урыны, телефоны, электрон почта адресы)» сүзләренә алмаштырырга.